# “Һәр җәүһәрдә - халкым тарихы”

## (Конспектлар, сценарийлар, татар халык уеннары җыентыгы)

Төзеде:
Хөснетдинова Л.Х.,
Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
МБМБУ “Кызыл Тау ”Аленушка”
балалар бакчасы”ның беренче
квалификацион категорияле
тәрбиячесе

# Эчтәлек


| | |
|---|---|
| **Белем бирү эшчәнлеге конспектлары** | |
| “Татар халкының милли киемнәре” | 3 бит |
| “Чигүле читекләрем” | 5 бит |
| “Татар халык ашлары” | 8 бит |
| “Серле сандык” | 12 бит |
| “Татар халык әкиятләре иленә сәяхәт” | 16 бит |
| **Сценарийлар** | |
| “Кунаклашу” (йола бәйрәме) | 20 бит |
| “Аулак өй” кичәсе | 23 бит |
| “Орчык бәйрәме” | 26 бит |
| “Һәр җәүһәрдә – халкым тарихы” кичәсе | 28 бит |
| **Татар халык уеннары** | 33 бит |

# Белем бирү эшчәнлеге конспектлары

## “Татар халкының милли киемнәре”

**Төркем:** мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь).

**Төп белем бирү өлкәсе:** танып белү үсеше.

**Интеграль белем бирү өлкәләре:** сөйләм үсеше, нәфис-нәфасәти үсеш.

**Максат:** Татар халкының милли киемнәре турында мәгълүмат бирү.

**Бурычлар:**

**Тәрбия бурычы:** балаларда татар милли киемнәренә, татар халкының үткәненә кызыксыну тәрбияләү.

**Үстерү бурычы:** сөйләм телен, фикерләү сәләтен, танып белү активлыгын үстерү.

**Белем бирү бурычы:** милли киемнәрнең исемнәрен, бизәлешләрен сөйләмдә куллануны системалаштыру.

**Сүзлек:** бәби (бала) итәкле күлмәк, алъяпкыч, билбау, тукыма, бәрхет, ефәк җепләр.

**Әзерлек эшләре:** презентация (“Милли бизәкләр”), дидактик уен (“Калфак, түбәтәй бизә”) әзерләү; калфак, түбәтәй турында матур әдәбият уку, әчтәлеге буенча әңгәмә үткәрү; “Түбәтәй” уенын өйрәнү; татар халык көйләре тыңлау.

**Җиһазлау:** ноутбук, экран, колонкалар, презентация (“Милли бизәкләр”), дидактик уен “Калфак, түбәтәй бизә”; күргәзмә - татар халкының милли киемнәре эленгән (күлмәк, камзул, алъяпкыч, ыштан, түбәтәй, калфак); “Тылсымлы түбәтәй” шигыре (Йолдыз); татар халык көйләре.

**Эшчәнлек структурасы:**

1. Исәнләшү. Оештыру моменты.

2.Татар милли киемнәре турында сөйләү.

3. Презентация карау (милли бизәкләр).

4. Дидактик уен “Калфак, түбәтәй бизә”

5. Шигырь уку “Тылсымлы түбәтәй”.

6. “Түбәтәй” уены.

7. Йомгаклау. Саубуллашу.

**Эшчәнлек барышы:**

**1. Оештыру моменты. Исәнләшү.**

**2. Татар милли киемнәре турында сөйләү.**

**Тәрбияче**: Балалар, карагыз әле (күргәзмәгә күрсәтә) бу нинди киемнәр? Кайсы халык киемнәре? Бу нәрсә? (*Балалар җаваплары: күлмәк, камзул, ыштан, калфак, түбәтәй...*)

**Тәрбияче**: Әйдәгез, һәрберсе белән якынрак танышыйк. Өс киемнәре - күлмәк белән ыштан (ирләрдә соңрак - чалбар). Ирләр күлмәге озын булган, ыштан (чалбар) өстенә төшеп торган. Хатын-кызларның күлмәге бәби итәкле булган (кабатлау: бәби итәкле күлмәк).

Монысы нәрсә? (*Балалар җаваплары: алъяпкыч*). Ай-яй нинди матур алъяпкыч! Ничек матур итеп татар бизәкләре белән чигелгән. Балалар, нәрсә соң ул – алъяпкыч? (*Балалар җаваплары*) Алъяпкыч – ул өс киемнәре пычранмасын өчен киелә торган әйбер. Аны ирләр дә, хатыннар да кигән.

Бу нәрсә? (*Камзул*). Ирләр аны өйдә кигәннәр. Ирләрнең камзуллары карарак төстәге тукымадан тегелгән, ә хатын-кызларныкы - ачыграк төстәге бәрхеттән, йә тукымадан.

Ә бу, балалар, билбау - ирләрнең өс киеме өстенә бәйләнгән (кабатлау: билбау).

Баш киемнәре. Ирләр баш киеме... – (*түбәтәй*). Борын-борыннан ирләр өйдә түбәтәй кияргә яратканнар. Байлар энҗеле яки алтын-көмеш җепләр белән чигелгән түбәтәй кигәннәр.

Хатын-кыз баш киеме... – (*калфак*). Калфакларның төрләре бик күп булган. Кечкенә калфак чәчкә кыстырып куела, аның өстенә шәл ябыла. Ә зур калфакны тулысынча башка кияләр. Татар кызлары калфакларны төрле төстәге ефәк җепләр белән чигеп, ташлар (энҗеләр) тагып бизәгәннәр.

**Тәрбияче**: Балалар, түбәтәй, калфак - алар нинди киемнәр? (*Балалар җаваплары: баш киемнәре*). Без кайсы халык киемнәре турында сөйләштек? (*Балалар җаваплары: татар халык киемнәре*) Әйе, бу татар халык киемнәре. Татар халык киемнәре бер-берсенә нәрсә белән ошаган? (*Балалар җаваплары: матур, бизәкле...*)

**Тәрбияче**: Балалар, татар халкының үз милли киеме, татар бизәкләре, гореф-гадәтләре бар. Әйдәгез, татар халкынын бизәкләре белән танышып китик.

**3. Презентация карау “Милли бизәкләр”.**

(Лалә, өчьяфрак, яфрак, кыңгырау, канәфер, чалмабаш, гөлҗимеш).

**4. Дидактик уен “Калфак, түбәтәй бизә”.**

**Тәрбияче:** Хәзер мин сезне калфак, түбәтәй бизәргә чакырам. Әзер бизәкләр белән кызлар калфак, малайлар түбәтәй бизи. *(Балаларның мөстәкыйль эшләре. Салмак кына татар халык көе яңгырый).*

**Тәрбияче:** Булдырдыгыз, балалар. Карагыз әле нинди матур булдылар. Балалар, сез нинди бизәкләр кулландыгыз? (*Балалар җаваплары*)

Балкып тора түбәтәй, калфаклар

Энҗе бөртекләре белән.

Алар монда килгән гүя

Чын әкият иленнән.

**Тәрбияче:** Балалар, сезнең тылсымлы түбәтәй турында ишеткәнегез бармы? (*Балалар җаваплары*) Нинди микән ул тылсымлы түбәтәй, беләсегез киләме?

**5. Шигырь уку “Тылсымлы түбәтәй”.**

**Тәрбияче:** Балалар, безнең түбәтәй дә тылсымлы микән? Тикшереп карыйбызмы? “Түбәтәй” уенын уйныйбызмы?

**6. “Түбәтәй” уены.** (*татар көе астында түбәтәйне бер-берсенә тапшыралар, кемдә түбәтәй кала, шул балага җәза бирелә*).

**7. Йомгаклау. Саубуллашу.**

## “Чигүле читекләрем”

**Төркем:** мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь).

**Төп белем бирү өлкәсе:** танып белү үсеше.

**Интеграль белем бирү өлкәләре:** сөйләм үсеше, нәфис-нәфасәти үсеш.

**Максат:** Балаларны татар халкының милли аяк киеме - читек белән таныштыру.

**Бурычлар:**

**Тәрбия бурычы:** балаларда матурлыкны күрә белү сыйфаты, зәвыклылык тәрбияләү.

**Үстерү бурычы:** бизәкләр төзү һәм эстетик зәвык белән урнаштыру күнекмәләре үстерү.

**Белем бирү бурычы:** өс-баш, аяк киемнәрен чагыштырырга, төркемнәргә аерырга өйрәтү.

**Сүзлек:** читек, чигүле, озын кунычлы, татар халык аяк киеме, орнамент.

**Әзерлек эшләре:** дидактик уен әзерләү – "Читекне бизә"; читек турында матур әдәбият уку; "Башмакчы" уенын өйрәнү.

**Җиһазлау:** ноутбук, экран, колонкалар, Татармультфильм студиясенең "СабанToYou" мультфильмы, читекләр, аудиоязма "Бииләр итек, читекләр", дидактик уен "Читекне бизә".

**Эшчәнлек структурасы:**

1. Исәнләшү. Оештыру моменты.
2. Мультфильмнан өзек карау.
3. Әңгәмә "Читек".
4. Җыр тыңлау: "Бииләр итек, читекләр".
5. Дидактик уен "Читекне бизә".
6. Тизәйткеч ятлау.
7. Уен "Башмакчы".
8. Йомгаклау. Саубуллашу.

## Эшчәнлек барышы:

**1. Оештыру моменты. Исәнләшү.**

**2. Мультфильмнан өзек карау (читек турында).**

**3. Әңгәмә "Читек".**

**Тәрбияче**: Балалар, сез мультфильмда нәрсәләр күрдегез? (*Балалар җаваплары*) Мультфильм геройлары нинди киемнәр кигәннәр? (*Татар халык киемнәре, камзул, күлмәк...*) Әйе, балалар, бик дөрес. Һәр халыкның үзенең милли киемнәре бар. Ә аякларына нәрсә кигәннәр, күрдегезме? Нәрсә икәнен беләсезме? (*Балалар җаваплары*) Балалар, (читек күрсәтә) бу – читек – татар халкының аяк киеме. (кабатлау)

Бизәк төшкән итекләрне

Читекләр дип йөрткәннәр

Аларны татар кызлары

Бәйрәмнәрдә кигәннәр.

(Читекләрне карау, алар турында сөйләү)

**Тәрбияче**: Балалар, читек нинди? (*Балалар җаваплары*) Читек - озын кунычлы күн аяк кием. Читекне ирләр дә, хатын-кызлар да кигән. Ирләр читеге кара күннән, йомшак итеп тегелгән. Хатын-кызлар чигүле, бизәкле читек кигән. Аеруча, лалә чәчәге бизәге кулланган. Балалар, республикабызда, Арча дигән шәһәр бар, ул бүгенге заман милли читекләрнең туган иле. Электән үк Арча яклары үзенең читекләре белән танылган, бу як хатын-кызлары башта аларны үзләренә чиккәннәр. Соңрак чиккән читекләргә сорау зур булгач, аларны күпләп җитештерә башлаганнар. Читекләр турында җырлар да бар. Читек турында җыр тыңлыйбызмы, балалар?

**4. Җыр тыңлау: "Бииләр итек, читекләр"** (Ш.Галиев сүз.).

**Тәрбияче**: бик күңелле, шаян җыр, әйеме, балалар? Аны ишеткәч күңелле булып китте, сезнең дә күңелләрегез күтәрелдеме? (*Балалар җаваплары*)

Ә хәзер, балалар, мин сезне читек бизәргә чакырам. Матур татар орнаментлары белән читек бизибезме?

**5. Дидактик уен "Читекне бизә".**

**Тәрбияче**: балалар, үзегезгә ошаган бизәкне кулланып, читекләрегезне бизи аласыз. Нинди бизәкләр кулланасыз? (*Балалар җаваплары*) Бигрәк матур читекләр килеп чыккан, әфәрин, балалар! Әйдәгез әле, читекләребез турында тизәйткеч өйрәнәбез.

**6. Тизәйткеч ятлау.**

Итек, читек, энә, без,

Матур итеп тегәбез.

**Тәрбияче**: читегебез тегелгән (читек күрсәтә), "Башмакчы" уенын уйныйбызмы?

**7. Уен "Башмакчы".**

**8. Йомгаклау. Саубуллашу.**

**“Татар халык ашлары”**

**Төркем:** мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь).

**Төп белем бирү өлкәсе:** танып белү үсеше.

**Интеграль белем бирү өлкәләре:** сөйләм үсеше, нәфис-нәфасәти үсеш.

**Максат:** Татар халкының милли ризыклары белән таныштыруны дәвам итү.

**Бурычлар:**

**Тәрбия бурычы:** балаларда кунакчыллык хисләрен, кунакларга карата хөрмәт сыйфатларын, табын әдәбен тәрбияләү.

**Үстерү бурычы:** балаларның игътибарлылыгын, уйлау сәләтләрен, хәтерләрен үстерү.

**Белем бирү бурычы:** татар милли ризыкларның исемнәрен ныгыту, көндәлек сөйләмдә кулланышка кертү.

**Сүзлек:** кунакчыллык, сый-хөрмәт, кыстап-кыстап, сыйладык, пәрәмәч.

**Әзерлек эшләре:** татар халык ашлары турында төшерелгән мультфильмнарны карау, матур әдәбият уку, табышмаклар, мәкальләр, җырлы уен өйрәнү - “Кунаклар”; “Кунак чакырдык”, “Кунакны сыйлыйбыз” темаларына әңгәмәләр үткәрү; ашъяулык бизәү.

**Җиһазлау:** ноутбук, колонкалар, милли ризык муляжлары, ашъяулык, татар халык көйләре, аудиоязма “Кунаклар”.

**Эшчәнлек структурасы:**

1. Исәнләшү. Оештыру моменты.
2. Әңгәмә “Кунак көтәбез”.
3. Уен-табышмак “Тылсымлы ашъяулык”.
4. Сүзле уен “Әйтеп бетер!”.
5. Җырлы уен “Кунаклар”.
6. Шигырь уку: В. Хәйруллина “Табын кагыйдәләре”.
7. Эндәш ятлау, “з” авазы.
8. Йомгаклау. Саубуллашу.

**Эшчәнлек барышы:**

**1. Оештыру моменты. Исәнләшү.**

*(Балалар түгәрәк ясап кереп басалар*.)

**2. Әңгәмә “Кунак көтәбез”**

**Тәрбияче:**

Кунакларны бик яраткан,

Электән безнең халык.

Юмарт диеп, уңган диеп,

Килгән күптән макталып.

- Балалар, бүген без татар халкының кунакчыллыгы турында сөйләшербез.

- Әйтегез әле, кешеләр ни өчен бер-берсенә кунакка йөриләр? (*Балалар җаваплары*)

- Кунак килгәнне яратасызмы? Ни өчен яратасыз*?* (*Балалар җаваплары*)

- Кунакны каршы алырга ничек әзерләнәбез? (*Балалар җаваплары*)

- Кунакны нинди сүзләр белән каршы алабыз? (*Балалар җаваплары*)

-Кунакның күңелен ничек итеп ачалар? (*Балалар җаваплары*)

(Самавыр җырлаган тавыш ишетелә)

**Тәрбияче:** Балалар, ишетәсезме, самавыр җырлый! Шундый юрау бар: “Самавыр җырласа – кунак килә”. Әби-бабаларыбыз элек-электән кунакчыл булган, кунакка ачык йөз, сый-хөрмәт күрсәткән. Кунак киләсе булса, мул итеп ризык пешерәбез. Килгән кунакны кыстый-кыстый сыйлыйбыз. Балалар, кунакны татар халкы нинди милли ризыклар белән сыйлый? Тылсымлы ашъяулык астында яшерелгән ризыкларны белер өчен, табышмакларга җавап бирергә кирәк.

**3. Уен-табышмак “Тылсымлы ашъяулык”**

- Йомырка белән онны

Бутап камыр басканнар.

Бәрәңге, ит, тоз салып,

Почмаклар ясаганнар. (Өчпочмак)

- Утырсам да мин менә

Тыйнак кына, тик кенә.

Эчем тулы ит, бәрәңге генә. (Бәлеш)

- Камыр эчендә бәрәңге

Йә, уйлап кара әле. (Кыстыбый)

- Чыж иттереп саласың,

Бик тиз генә аласың.

Балга манып кабасың.

Ул нәрсә?   (Коймак)

- Баллы да, тәмле дә,

Өстәлне бизи... (Чәк-чәк**)**

- Иттән генә торам мин

Майга чумып чыгам мин. (Пәрәмәч)

- Аңа ит, токмач,

Кишер, суган, тоз салалар. (Токмачлы аш)

**Тәрбияче**: Булдырдыгыз, балалар! Кунакчыллык турында халкыбыз бик мәгънәле сүзләр дә әйткән. Әйдәгез әле бергә искә төшерик.

**4. Сүзле уен "Әйтеп бетер!"**

- Коры табынга кунак *(утыртмыйлар)*.

- Кунаклы йорт *(хөрмәтле йорт)*.

- Кунак ашы *(кара каршы)*.

- Кунак кадерле булса, *(самовыр тиз кайный)*.

**Тәрбияче**: Менә бит, балалар, нинди мәгънәле, дөрес сүзләр. Алар  элек-электән, телдән-телгә күчеп килгәннәр. Сез дә аларны истә калдырырга тырышыгыз.

**Тәрбияче:** Кунакны сыйлау - үзе бер хөрмәт, ләкин аның күңелен дә күрә белергә кирәк, балалар. Әйдәгез әле  "Кунаклар" җырлы уенын уйнап алыйк.

**5. Җырлы уен "Кунаклар"**

*(Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә басалар)*

Ямьле матур көн иде,

Чакырдык без кунаклар.

Кунакларны сыйларга,

Салдык майлы коймаклар.

Чыж-чыж итеп коймаклар *(Балалар кулларын як-якка җәяләр),*

Җәелде, әй, җәелде.

Менә тагын кечкенә

Булып калды, җыелды (*Кысылалар),*

Җыелды, әй, җыелды.

Аннан ары кабарды *(Кулларын югары күтәрәләр),*

Кабарды,әй, кабарды.

Шиңде, юп-юка калды (*Чүгәлиләр),*

Пеште инде коймаклар.

Сыйландылар кунаклар,

Тордылар, баш иделәр *(Баш ияләр.)*

Таралдылар, әй, шатлар.

**Тәрбияче:** Балалар, ә сез табын янында әдәпле утыру кагыйдәләрен беләсезме? (*Балалар җаваплары*)

**6. Шигырь уку: В. Хәйруллина "Табын кагыйдәләре"**.

**Тәрбияче:** Шигырьдә нинди кагыйдәләр турында әйтелә? Нинди киңәшләр бирелә? (*Балалар җаваплары*) Тагын сез табын янында үз-үзеңне тотуның нинди кагыйдәләрен беләсез? (*Балалар җаваплары*)

**Тәрбияче:** Сезне кайбер кагыйдәләр белән таныштырасым килә:

- ашарга утырган вакытыгызда, иң элек кулларыгызны юыгыз һәм яхшылап сөртегез;
- үзегездән олы кешеләр булганда, алардан алдан утырмагыз;
- ризыкны зур-зур алмагыз, выз тутырып капмагыз, ашыкмагыз, яхшы чәйнәгез, кул, киемнәрегезне буямагыз, башкаларның ашавына карап тормагыз, күп ашарга гадәтләнмәгез;
- ашаганнан соң кулларыгызны, авызыгызны юыгыз.

**7. Эндәш ятлау, "з" авазы**.

Әйдә безгә килегез!

Капкалардан керегез.

Капкалардан керегез,

Өебезгә үтегез.

Өебезгә үтегез,

Кунак булып китегез.

Кунак булып китегез, -

Гөрләп бәйрәм итегез!

**8. Йомгаклау. Саубуллашу.**

## “Серле сандык”

**Төркем:** мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь).

**Төп белем бирү өлкәсе:** танып белү үсеше.

**Интеграль белем бирү өлкәләре:** сөйләм үсеше, нәфис-нәфасәти үсеш, социаль-коммуникатив үсеш.

**Максат:** Татар халкының милли киемнәре, бизәкләре, ризыклары турында белемнәрен арттыру, ныгыту.

**Бурычлар:**

**Тәрбия бурычы:** халык сәнгате аша балаларда зәвык тәрбияләү.

**Үстерү бурычы:** балаларның сүз байлыгын, логик фикерләү сәләтен, хәтерләрен үстерү.

**Белем бирү бурычы:** милли киемнәрне, ризыкларны, татар бизәкләрен аера һәм аларның исемнәрен әйтә белергә йөрәтүне дәвам итү.

**Сүзлек:** бәби (бала) итәкле күлмәк, камзул, алъяпкыч, яулык, читек, чулпы, орнамент, кунакчыл.

**Әзерлек эшләре:** презентация әзерләү – “Серле сандык”, ИКТ уены (“Милли ризыклардан табын әзерлә”); калфак, түбәтәй турында матур әдәбият уку; татар халык ашлары турында төшерелгән мультфильмнарны карау, эчтәлеге буенча әңгәмә үткәрү; “Яулык салыш” уенын өйрәнү; татар халык көйләре тыңлау.

**Җиһазлау:** ноутбук, экран, колонкалар, презентация (“Серле сандык”), кисмә рәсемнәр (татар бизәкләре), татар халык көйләре, аудиоязма “Шома бас”, “Әпипә” (диск “Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе” методик әсбап өчен аудио-кушымта), калфаклар, түбәтәйләр, чиккән кулъяулык, брошка ясар өчен һәр балага фетр, фоамираннан киселгән әзер элементлар (лалә чәчәге, яфрак).

**Эшчәнлек структурасы:**

1. Исәнләшү. Оештыру моменты.

2. Әңгәмә “Сандык”.

3. Мультимедиа презентация карау: “Серле сандык”.

4. Үстерешле уен “Бу нинди бизәк?”.

5. Уен “Яулык салыш”.

6. ИКТ уены “Милли ризыклардан табын әзерлә”.

7. Остаханә “Милли брошка”.

8. Йомгаклау. Саубуллашу.

**Эшчәнлек барышы:**

**1. Оештыру моменты. Исәнләшү.**

“Әйлән-бәйлән уйныйбыз” көенә балалар чыгалар, түгәрәккә басалар.

**Тәрбияче**: Исәнмесез, балалар!

Дуслар елмаеп караса,

Дөнья яктырып китә.

Я, кайсыгыз дусларына

Елмаю бүләк итә?

Балалар, сез елмайгач, бүлмә дә матурланып, яктырып китте.

(Серле тавыш ишетелә) Балалар, ишетәсезме? Бу нинди тавыш?

(Слайд 1 - Экранга сандык чыга)

**2. Әңгәмә “Сандык”.**

**Тәрбияче**: Карагыз әле, бу нәрсә? (*Балалар җаваплары*) Әйе, бу сандык. Сандык нинди? (*Балалар җаваплары*) Сезнең әбиләрегездә сандык бармы, балалар? Ә тагын кая да булса сезнең сандык күргәнегез бармы? Аның эчендә нәрсәләр саклана, беләсезме? (*Балалар җаваплары*) Ә бу серле сандыкта нинди хәзинәләр бар икән, беләсегез киләме? (*Балалар җаваплары*) Бер, ике, өч!

(Слайд 2 – татар халык киемнәре)

**3. Мультимедиа презентация “Серле сандык”**

(Татар халык киемнәре белән танышу)

**Тәрбияче**: Балалар, бу нәрсәләр? (*Киемнәр - күлмәк, камзул, ыштан*). Мондый татар халык киемнәрен элек әби-бабаларыбыз кигән. Менә бу - бәби итәкле күлмәк. Бергәләп кабатлыйк әле: “бәби итәкле күлмәк”. Балалар, ә сезнең мондый киемнәр

кигәнегез бармы? (*Балалар җаваплары*) Әйе, без дә татар бәйрәмнәрендә шундый матур татар халык киемнәрен киябез.

(слайд 3 – алъяпкыч)

**Тәрбияче**: Бу нәрсә? (*Балалар җаваплары*) Монысы алъяпкыч, чөнки аны алга бәйләгәннәр. Әби-апаларыбыз ашарга пешергәндә шундый матур алъяпкычларны киеп тәмле ризыклар пешергәннәр.

(слайд 4 – милли киемнәр)

Балалар, бу киемнәр милли киемнәр дип атала. Әйдәгез, бергә кабатлыйк әле: “милли киемнәр”.

(слайд 5 – калфак, яулык, түбәтәй)

**Тәрбияче**: Бу нәрсә? (*калфак*) Әйе, хатын-кызларның баш киеме. Калфак нинди? (*Балалар җаваплары*) Бизәкләп, матурлап эшләнгән. Ә бу нәрсә – кем белә? (яулык күрсәтелә). Бу – яулык, ашарга пешергәндә ризыкка чәч төшмәсен өчен, аны башка бәйләп куялар. (Түбәтәй күрсәтелә) Балалар, карагыз әле, ә менә бу баш киеме сезгә барыгызга да таныштыр. Нәрсә ул? (*Балалар җаваплары*) Дөрес, бу түбәтәй. Түбәтәйне кемнәр кия, балалар? (*Балалар җаваплары*) Әйе, безнең бабайларыбыз, әтиләребез, малайларыбыз әле дә мондый матур түбәтәйләрне киеп йөриләр. Балалар, сезнең дә калфак, түбәтәй киеп карыйсыгыз киләме? (*Балалар җаваплары*) Килегез әле, карагыз нинди матур бизәкле калфаклар, түбәтәйләр *(башларына кияләр).* (*Калфак, түбәтәй турында шигырьләр сөйлиләр*)

**Тәрбияче**: Балалар, калфак, түбәтәй – татар халкының милли баш киемнәре.

Балалар, сандыкта тагын нәрсәләр бар карыйбызмы?

(слайд 6 – читек)

**Тәрбияче**: Бу нәрсә, беләсезме? (*Балалар җаваплары*) Бу - читек. Аларны кызлар да, малайлар да кигәннәр. Бик матур, уңайлы, чигелгән аяк киеме ул.

Балалар, читекне милли аяк киеме дип йөртәләр.

(слайд 7 – бизәксез киемнәр)

**Тәрбияче**: Балалар, карагыз әле, киемнәр нишләгән? (*Балалар җаваплары*) Киемнәрнең бизәкләре юкка чыккан. Ничек аларга яңадан матур татар бизәкләрен кайтарырга икән? Балалар, әйдәгез әле бизәкләрне искә төшерик, “Бу нинди бизәк?” уенын уйнап алыйк.

**4. Үстерешле уен “Бу нинди бизәк?””** (Кисмә рәсемнәрне җыю)

**Тәрбияче**: Балалар, конвертларда бизәк төшерелгән кисмә рәсемнәр бар. Аларны җыярга һәм нинди бизәк төшерелгәнен әйтергә кирәк. Парлап эшлибез. *(милли көй яңгырый, бизәкләрне җыялар, исемен, төсен әйтәләр*).

Татар халык киемнәрен нинди бизәкләр белән бизәгәннәр? *(Балалар җаваплары: өчьяфрак, лалә, канәфер, кыңгырау, яфрак)*

(слайд 8 – татар бизәкләре белән милли киемнәр)

Балалар, экранга карагыз әле! Киемнәрнең бизәкләре яңадан күренә, бик матур булдылар, әйеме, балалар? Бу бизәкләрне икенче төрле орнамент диләр. Кабатлыйк әле: орнамент. Булдырдыгыз, балалар! Серле сандыкта тагын нәрсәләр бар, карыйбызмы?

(слайд 9 – сөлге, кулъяулык)

**Тәрбияче**: Балалар, орнамент белән киемнәрне, калфак, түбәтәй, читекләрне генә түгел, ә сөлге, кулъяулыкларны да бизәгәннәр. (*Чиккән сөлге, кулъяулыклар карау*). Балалар, минем дә чиккән кулъяулыгым бар, карагыз әле нинди матур бизәкле. Кулъяулык белән “Яулык салыш” уенын уйныйбызмы?

**5. Уен “Яулык салыш”**

(*милли көй яңгырый, балалар түгәрәктә. Көй башлануга яулык кулдан-кулга түгәрәк буйлап җибәрелә. Көй туктауга яулык кемдә кала, шул җәза ала*)

(слайд 10 – китап “Татар халык ашлары”)

**Тәрбияче**: Балалар, бу нәрсә? (*Балалар җаваплары*) Бу – “Татар халык ашлары” китабы. Без әби-бабаларыбызның бик кунакчыл булуын, кунак киләсе булса, күп итеп ризык (татар халык ашлары) пешерүләрен беләбез. Без дә бу китапта булган милли ризыклардан табын әзерлибезме? (*Балалар җаваплары*)

**6. ИКТ уены “Милли ризыклардан табын әзерлә”**

(слайд 11 – өстәл)

**Тәрбияче**: Татар халкы кунакны нинди милли ризыклар белән сыйлый? (*Балалар татар халык ашларын әйтәләр, кабатлыйлар*). Булдырдыгыз, балалар, әфәрин! Сандыкта тагын нәрсәләр калды икән, балалар? Карыйбызмы?

(слайд 12– бизәнү әйберләре)

**Тәрбияче**: Хатын-кызлар элек тә бик яратып бизәнү әйберләре такканнар. Бу нәрсәләр? (*Балалар җаваплары: алка, брошка*) Монысы, балалар, чулпы.

(слайд 13 – бизәнү әйберләре таккан татар кызы)

Балалар, чулпыны бау белән үрелгән чәчкә бәйләгәннәр. Элек-электән, татар халкы матурлык яраткан. Матур киемнәр тегеп, аларга матур бизәкләр ясап, чигеп киенгәннәр, аякларында матур итеп бизәлгән читекләр, башларында чигелгән калфаклар булган. Балалар, сезнең дә татар бизәкләре белән матур брошка ясыйсыгыз киләме? (*Балалар җаваплары*)

**7. Остаханә "Милли брошка"**

**Тәрбияче**: Балалар, үрнәккә карагыз әле. Монда нинди бизәкләр бар? (*Балалар җаваплары: лалә чәчәге, яфрак*). Балалар, сезнең алда брошка ясарга, барлык элементлар да әзерләнгән, аларны үрнәктә шикелле ябыштырасы була. (*татар халык көенә эшлиләр*). Балалар, карагыз әле, нинди матур, татар бизәкле брошкалар килеп чыкты. Әфәрин!

**8. Йомгаклау. Саубуллашу.**

## "Татар халык әкиятләре иленә сәяхәт"

**Төркем:** мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь).
**Төп белем бирү өлкәсе:** сөйләм үсеше.
**Интеграль белем бирү өлкәләре:** танып белү үсеше, иҗтимагый аралашу үсеше.
**Максат:** информацион-коммуникатив технологияләр кулланып, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм телен үстерү, дөрес сөйләм формалаштыру.
**Тәрбия бурычы:** әкият нигезендә балаларда шәфкатьлелек, миһербанлылык, дуслык, гаделлек, әдәплелек, ярдәмчеллек хисләре, китапка мәхәббәт тәрбияләү.
**Үстерү бурычы:** бәйләнешле сөйләмне, фикерләү, хәтер сәләтен үстерү, сүзлекләрен баету.
**Белем бирү бурычы:** балаларның сөйләмдә мәгънәсе капма-каршы булган сүзләрне, сыйфатларны урынлы куллана белүне, җөмләләр төзергә өйрәнүне дәвам итү.
**Сүзлек:** бөртекләр, үрмәкүч, ташбака, торна, җеп эрләү.
**Әзерлек эшләре:** «Кайсы әкият кирәк-яраклары?» ИКТ уенын, татар халык әкиятләренә рәсемнәр әзерләү, балалар белән татар халык әкиятләрен уку, әкиятләр буенча төшерелгән мультфильмнарны карау, эчтәлекләре буенча әңгәмәләр үткәрү, әкият геройларына хас сыйфатларны ачыклау, эш-гамәлләрен анализлау, «Капкалы» хәрәкәтле уенын өйрәнү, капма-каршы булган сүзләрне кабатлау.

**Җиһазлау:** проектор, ноутбук, колонкалар, «тылсымлы» китап, ИКТ уены «Кайсы әкият кирәк-яраклары?», татар халык көе, аудиоязмалар, карта, медальоннар.

**Эшчәнлек структурасы:**

1. Оештыру өлеше. Исәнләшү.
2. Уен-табышмак “Әкиятне бел!”
3. [У], [ү] авазларының дөрес әйтелешен ныгыту (калын һәм нечкә сузыклар).
4. ИКТ уены: “Кайсы әкият кирәк-яраклары?”
5. Сүзле уен: “Киресен әйт!”
6. “Өч кыз” өстәл театры.
7. Йомгаклау, саубуллашу.

**Эшчәнлек барышы:**

**1. Оештыру өлеше. Исәнләшү.**

*(Балалар түгәрәккә басып бер-берсе белән исәнләшәләр)*

Мин иртә белән бакчага киләм,
Иптәшләремнең хәлләрен беләм.
Исәнме, ...,
Исәнме, ...!
Сезгә, дусларым,
Иртәнге сәлам!

**Тәрбияче**: Балалар, беләсезме, бүген эшкә барганда, миңа кем очрады?! *(Балалар җаваплары)*. Ягымлы бер әби очрады. Ул миңа сезгә дип, күчтәнәч биреп җибәрде. Сез табышмаклар яратасызмы? *(Балалар җаваплары)*. Күчтәнәчнең нәрсә икәнен мин табышмак белән әйтәм, тыңлап карагыз әле:

Тавышсыз, кулсыз булса да,
Күп сүзле, күп рәсемле.
Нинди тылсымлы әйбер ул?
Син, дускай, беләсеңме? (*Китап*).

*(Балалар җаваплары)*.

**Тәрбияче**: Дөрес, балалар, китап. *(Тәрбияче китапны күрсәтә)*.

<u>Аудиоязма 1:</u> «Исәнмесез, балалар! Мин - тылсымлы китап. Сезгә кунакка килүемә бик шат! Мин сезне татар халык әкиятләре иленә сәяхәткә чакырам».

*(Китапны карыйлар)*

**Тәрбияче**: Балалар, сәяхәткә барабызмы? (*Балалар җаваплары)*.

**Тәрбияче**: Әйдәгез, китапны ачып карыйбызмы? *(Китапны ачалар)*.

**Китапның 1нче бите** (“Әкиятне бел!” рәсем буенча әкиятне танырга кирәк)

**Тәрбияче**: Балалар, сез әзерме? Игътибар белән карагыз!

**2. Уен-табышмак “Әкиятне бел!”**

1) “Өч кыз”.
2) “Алтын бөртекләр”.
3) “Ике кыз”.

4) “Төлке һәм каз”.
5) “Әтәч белән тавык”.
**Тәрбияче**: Бик дөрес, булдырдыгыз. Балалар, әтәч ничек кычкыра әле? (*Балаларның җаваплары).*
**Тәрбияче:** Сезнең дә әтәчләр кебек кычкырып карыйсыгыз киләме? (*Балаларның җаваплары).*
**3. [У], [ү] авазларының дөрес әйтелешен ныгыту (калын һәм нечкә сузыклар).**
Кикрик-ү-ү-үк!
Өс бөтен,
Тамак ту-у-у-ук!
Тавыгым кү-ү-ү-үп,
Баш астында мендәр юу-у-у-ук!
**Тәрбияче:** Яхшы, балалар, бу биремне үтәдегез. Китап белән танышуыбызны дәвам итәбезме? Алга таба – сәяхәткә!
Аудиоязма 2: (Елаган тавыш) “Әкиятләрнең кирәк-яракларын убырлы сихерләгән, адаштырган. Аларны үзләренең әкиятләренә кайтарырга ярдәм итегез...”.
**Тәрбияче:** Балалар, ярдәм итәбезме? (*Балаларның җаваплары).*
**Китапның 2нче бите** (“Кайсы әкият кирәк-яраклары?” ИКТ уены тәкъдим ителә)
**4. ИКТ уены: “Кайсы әкият кирәк-яраклары?”**
(слайдлар: кәрзин, тәлинкә, алтын алма...)
**Балалар:** “Ике кыз”, “Төлке һәм торна”, “Алтын алма” әкиятеннән...... (Әкиятләр буенча әңгәмә оештыру).
**Тәрбияче:** Әкият кирәк-яракларын үз әкиятләренә кайтардыгыз, булдырдыгыз, балалар. Сезгә сәяхәт ошыймы? Китап безгә алга таба нәрсәләр әзерләде икән, карыйбызмы? (*Балаларның җаваплары).*
**Китапның 3нче бите** (“Киресен әйт!” - сүзле уен уйнау)
**5. Сүзле уен: “Киресен әйт!”**
*(Түгәрәктә балалар татар халык бию көенә биеп йөриләр, ә ике бала кара-каршы басып, кулларын югары күтәреп, “капка” ясыйлар. Көй туктагач, алар кулларын төшерәләр. “Капка” эчендә калган бала сүзнең киресен әйтә):*
Матур – ямьсез, тиз – экрен, җиңел – авыр, тырыш – ялкау, яхшы – начар, батыр – куркак, зур – кечкенә, озын – кыска, көн – төн, биек – тәбәнәк.
**Тәрбияче**: Бик күңелле уйнадык! Сәяхәтне дәвам итәбезме? (*Балалар җаваплары).*
Аудиоязма 3: “Әкиятнең хәрефләре югалган, рәсемнәре генә калган. Хәзер әкиятне ничек укырга инде?”
**Тәрбияче**: Балалар, тылсымлы китапта бер әкиятнең сүзләре юкка чыккан, әкият геройлары рәсемнәре генә калган. Нишләргә инде хәзер? Игътибар белән карагыз әле. Сез бу геройларны таныйсызмы? (*Балаларның җаваплары:* ташбака, үрмәкүч, тиен...*).* Алар нинди әкияттән, кем белә? *(“Өч кыз” әкиятеннән)*
**Тәрбияче**: Бик дөрес әйтәсез, балалар. Алар “Өч кыз” әкиятеннән, бүген безгә дә кунакка килгәннәр алар (Өстәл театрын күрсәтә), якынрак барып карыйбызмы? Ә

сез ул әкиятне беләсезме? (*Балалар җаваплары)*. Димәк, без әкиятне сөйли алабыз. Әйдәгез, бергәләп, әкиятнең эчтәлеген искә төшереп алабыз. Сез ризамы? Кемнәр бар соң бу әкияттә? (*Балаларның җаваплары:* Әни, Олы, Уртанчы, Кече кызлар, Тиен). Бик дөрес әйтәсез, балалар. "Өч кыз" әкиятен рольләргә бүлеп уйныйбызмы? (рольләрне бүлү)

**6. "Өч кыз" өстәл театры.**

**Тәрбияче:** Рәхмәт, балалар, булдырдыгыз! Сезгә әкият уйнарга ошадымы? (*Балаларның җаваплары).*

**Китапның ахыргы бите** (карта рәсеме)

<u>Аудиоязма 4</u>: "Балалар, безнең сәяхәт ахырына килеп җитте. Сез бик тырыш булдыгыз, миңа ярдәм иттегез. Мин сезгә бүләк әзерләдем. Картадан карап сез аны таба аласыз. Рәхмәт. Саубулыгыз".

(*Балалар картаны карыйлар, бүләкне эзләп табалар)*

**Тәрбияче**: Барлык биремнәрне дә уңышлы үтеп чыккан өчен тылсымлы китап сезгә буягычлар әзерләгән, "Мин әкиятче" медальләре калдырган. Хәзер сез чын әкиятчеләр! Сез шатмы, балалар? (*Балаларның җаваплары)*.

**7. Йомгаклау, саубуллашу.**

# Сценарийлар

**“Кунаклашу” (йола бәйрәме)**

**Төркем:** мәктәпкә әзерлек төркеме балалары өчен (6-7 яшь).
**Максат:** балаларга татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары аша сәнгати-эстетик тәрбия бирү.
**Бурычлар:**
- төрле милләт халкына ихтирам, горурлык хисләре тәрбияләү;
- сәнгатьле сөйләм телен үстерү;
- балаларда татар халкының уеннарына, җыр-биюләренә мәхәббәт уяту.

**Җиһазлау:**
Зал матур итеп бизәлгән: түрдә өй күренеше - самавыр, чынаяклар, татар халык ашлары (бәлеш, өчпочмак, кыстыбый, чәк-чәк һ.б.) куелган өстәл, өстәлгә татар орнаментлары төшерелгән эскәтер җәелгән; залның бер ягында ярминкә оештырыла: көнкүреш товарлары (уклау, орчык, кәрзин, агач кашыклар, табагач һ.б.), татар халкының баш, өс киемнәре (түбәтәй, калфак, камзул, читек һ.б.); мамык шәлләр; чиккән сөлгеләр, кульяулыклар; аудиоязмалар: татар халык көе “Галиябану”, “Кунаклар” (минус), “Дуслык турында җыр” (минус), «Шәл бәйләдем» татар халык җыры, “Зәңгәр чәчәк” җыры (уен өчен мендәр), татар, рус, мордва, чуваш, башкорт, мари, удмурт бию көйләре; музыкаль центр, ноутбук, колонкалар.
**Бәйрәм барышы:**

*Татар халык көе “Галиябану” яңгырый*

**Алып баручы:** Исәнмесез! Хәерле көн, кадерле балалар, кунаклар! Бүген без сезнең белән татар халкының иң зур йолаларыннан саналган «Кунаклашу» бәйрәмен искә алырбыз. Татар халкы элек-электән кунакчыллыгы белән аерылып торган. Көз һәм кыш алды – авылда муллык чоры һәм аңа туган-тумачаларның, дус-ишләрнең, егетләр һәм кызларның бер-берсенә кунакка йөрешүе хас булган. Кунаклар базар көн алдыннан килеп төшә торган булганнар, туган-тумачаларга, дус-ишләргә кунакка барганнар, күңел ачканнар.
*(Өй эче: Өй хуҗалары һәм 3-4 кыз кунаклар килүгә өстәл әзерлиләр)*
**Өй хуҗасы:** Кызым, самавыр чыжлый! Кунаклар күренми микән, карап кер әле!
**Кыз:** Кунаклар килә! Кунаклар килә! - *дип өйгә йөгереп керә һәм бергәләшеп кунакларны каршы алырга әзерләнәләр.*
**Хуҗалар:** Исәнмесез!
**Татар кызы:** Исәнмесез!
**Рус малайлары:** Здравствуйте!
**Башкорт:** Хаумыхыгыз!
**Удмурт:** Зечбуресь!
**Мордва:** Шумбратада!
**Мари:** Салам лийже!
**Чуваш:** Сывлах сунатап!
**Өй хуҗасы кызы**:
Капкалардан эз кергән,
Безнең өйгә кем килгән?

Кем килгән дип сорамагыз,
Кадерле дуслар килгән.
**Кунак кызы**:
Ак өйләргә кергәннәр
Ак челтәрләр элгәннәр,
Самавыр кайнап тора,
Без килгәнне белгәннәр.
*(Күрешә-күрешә кунакларны каршылыйлар, табынга утырталар.)*
**Алып баручы:** Ә хәзер, кадерле кунаклар, без сезне табынга чакырабыз! Рәхим итегез!

*Җыр: Шәүкәт Галиев "Кунаклар"*

**Кунак кызы**:
Ашадык, эчтек бик зур рәхмәт сезгә. Ә хәзер , әйдәгез, дуслар, күңел ачыйк, биеп алыйк.
- Әйдәгез!

*Татар биюе*

**Бала**:
Тыпыр-тыпыр берәү бии,
Аягында чабата.
Чабатасы да чабата,
Аны кемнәр ярата?

*Рус биюе*

**Бала**:
Биюләре, биюләре,
Биюләре бик чибәр.
Биюченең күңеле булсын,
"Ай, маладис!", дип җибәр.

*Чуваш биюе*
*Мари биюе*

**Бала**:
Әйдә, әйдә,
Әйдә биик!
Тыпыр-тыпыр биибез!
Көе килми димибез!

*Удмурт  биюе*
*Мордва биюе*
*Башкорт (курайда уйный).*

**Хуҗа**:
Кадерле кунаклар, ә хәзер без сезне
**Ярминкәгә чакырабыз!**
**Рәхим итеп килегез,**
**Тәмле сыйлар, шәп товарлар**
**Сезне көтә, күрегез!**

*Күңелле көй яңгырый*

*(Ярминкәгә баралар). (Бүлмәнең бер почмагында ярминкә оештырыла).*
**Сатучы**:

Калфак сатам, кәләпуш сатам
Дарым–шарым, тәңкә ярым
Күпмегә алсаң шуңа сатам.
**Балалар:** Безгә кирәк, без алабыз.
**Көнкүреш товарлары сатучы:**
Ни кирәк, шул бар!
Җаның теләгәнен сайлап ал.
Чүлмәк, орчык, көянтә
Дустым, сатып ал әйдә.
**Балалар:** Безгә кирәк, без алабыз. *(берсе орчык сатып ала).*
**Алып баручы:** Балалар, аулак өйләрдә кич утырганда кызлар ничә орчык җеп эрли, ул шулкадәр уңган саналган. Ә орчыкны эш коралы буларак кына түгел, уен өчен дә кулланганнар. Яратып "Орчык бөтерү" уенын уйнаганнар. Сезнең дә "Орчык бөтерү" уенын уйныйсыгыз киләме?
**Балалар:** Әйе.

*"Орчык бөтерү" уены (Татар көе яңгырый)*
*(Шигыр укыйлар, мәкал, табышмак әйтәләр, әтәч булып кычкалар, бииләр һ.б.).*

**Алып баручы:** Менә шулай күңелле итеп әби-бабаларыбыз эшли дә, ял да итә белгәннәр.
**Сатучы**:
Сабантуй сөлгеләре,
Каештыр өлгеләре...
Чигүчесе кем икән соң,
Кемнәрнең сөлгеләре?
Сөлге сатам кем ала?
**Балалар:** Безгә кирәк, без алабыз.
**Сатучы**:
Шәл сатам! Ефәк сатам!
**Балалар:** Безгә кирәк, без алабыз.
**Алып баручы:**
Оренбурдан мамык шәлләр алдым,
Алтын тәңкә бирдем җәлләми.
Алтын тәңкә бик зур мал түгел,
Бер күрешүләр әллә ни!

*Бию «Шәл бәйләдем»*

**Бала**:
- Егетләр, кызлар, инде кичке уеннар вакыты да җиткән бит! Әйдәгез, уйнарга!
- Әйдәгез!
**Алып баручы:** Балалар, нинди уен уйныйбыз?
(*Санамыш ярдәмендә уенны алып баручы сайлана)*

*"Зәңгәр чәчәк" уены*
*"Капкалы" җырлы-биюле түгәрәк уены*

**Алып баручы:**
Төн урталарына кадәр гармун, скрипка тавышы яңгыраган, егетләр һәм кызлар әйлән-бәйлән уйнаганнар, биегәннәр, җырлаганнар.

*(Барысы да ярым түгәрәк ясап басалар,*
*"Дуслык турында җыр" башкаралар)*

**“Аулак өй” кичәсе**

**Төркем:** мәктәпкә әзерлек төркеме балалары өчен (6-7 яшь).

**Максат:** балаларда халкыбызның йола бәйрәмнәренә кызыксыну уяту.

**Бурычлар:**

- туган телебезгә, халкыбызның йола-бәйрәмнәренә хөрмәт хисләре тәрбияләү;
- сөйләм телен үстерергә һәм иҗади сәләтләрен ачарга булышлык итү;
- балаларны милли йолалар белән якыннан таныштыруны дәвам итү.

**Җиһазлау:**

зал түрендә өйнең эчке күренеше; идәндә тукыган паласлар җәелгән; татар орнаментлары төшерелгән эскәтер белән өстәлдә татар халык ашлары муляжлары (бәлеш, өчпочмак, кыстыбый, чәк-чәк һ.б.) куелган; аудиоязмалар: татар халык көе “Галиябану”, “Әпипә”,  “Чума үрдәк, чума каз”, татар халык бию көе, яулык (“Утыр, утыр, Мәликә” уены өчен), ноутбук, колонкалар.

**Бәйрәм барышы:**

**Хуҗа кыз:** Әти-әни өйдә юк. Әбием кунакка китте. Аулак өйгә кызлар чакырыйм әле! (*ишектән чыгып китә)* Кызлар, кызлар! Аулак өйгә килегез! *(өйгә керә, идән себерә, паласларны төзәтә, өстәлне сөртә)*

*Салмак кына “Галиябану” көе уйный. Бераздан, кул эшләре тотып, кызлар керә башлый - барысы да милли киемнән. Сөенәләр, кочаклашалар.*

**1 нче кыз:** Исәнмесез, дусларым!
Хәерле кичләр булсын!

**2 нче кыз:** Бүген сездә аулак өй дип
Дусларымнан ишеттем,
Йомгагымны чорнарга дип
Мин сезгә килеп җиттем.

**Хуҗа кыз:** Исәнмесез! Хәерле кич!
Рәхим итегез түрдән! *(кызлар утырып кул эшләренә керешәләр)*

**3 нче кыз**: Кызлар, эшләгәндә берәр җыр җырласак эшләребез дә тизрәк эшләнер, күңелле дә булыр иде. Әйдәгез әле үзебезнең “Туган тел”ебезне җырлыйк. *(“Туган тел” җыры башкарыла)*

**4 нче кыз:** Кызлар, бергә җыелгач, борынгы уеннарның берсе - “Йөзек салыш” уенын уйнап алыйк?

**Уен: “Йөзек салыш”** (салмак кына татар халык көе яңгырый)

Мин башлыйм:

Иске уен, кызык уен –

“Йөзек салыш” уены.

Уч төбеңә йөзек салам –

Кемдә йөзек сикереп чык.

**1 нче кыз:** Моңа нинди җәза бирәбез?

- Тизәйткеч сөйләсен.

**2 нче кыз:** Моңа нишләргә?

- Шигырь сөйләсен...

- Табышмак әйтсен... (Яңа гына идем итек, “ч” өстәгәч булдым...(*читек*)

- Биесен... (**Татар халык биюе)**

**Егетләр:** Әй, кызлар ачыгыз ишекне, безнең дә уйныйсыбыз килә.

**Кызлар:**

Егетләр килгәннәр,

Безнең монда җыелганны,

Әллә каян белгәннәр. (Егетләр өйгә керәләр).

**Егетләр:**

Ай, кызлары, кызлары,

Янып тора күзләре.

**Кызлар:**

Безнең авыл егетләре

Берсеннән-берсе матур.

Үзе матур, сүзе матур,

Туган илдә бер батыр.

**Егетләр:**

Безнең авылның кызлары

Берсеннән-берсе чибәр,

Шул чибәрләр хөрмәтенә

Өздереп җырлап җибәр.

(Балалар татар халык бию такмагын җырлыйлар «Әпипә»).

**Егетләр:**

Бас кызым, Әпипә,

Син басмасаң, мин басам.

**Кызлар:** Синең баскан эзләреңә

Мин дә китереп басам.

Бас, кызым, Әпипә,

Син басмасаң, мин басам.

**Егетләр:**

Әпипәнең калачларын

Ашап калыйм ичмасам. *(Көләләр)*

**1 нче кыз:** Әйдәгез, бергә уйнап алабыз.

- Нинди уен уйныйбыз?

- Дуслар, әйдәгез “Чума үрдәк, чума каз” уенын уйныйбыз.

**“Чума үрдәк, чума каз” уены**

**“Утыр, утыр, Мәликә” уены**

**Хуҗа кыз:**

Кунак килсә сый-хөрмәтсез

Камыр-ашсыз булмый бит.

Кем нинди татар ашлары белә?

Я, дуслар, әйтеп карыйк.

*(Балалар халык ашларын әйтешәләр: чәк-чәк, өчпочмак, коймак, бәлеш, кыстыбый, кош теле һ.б.)*

**Кунак кызы:** Бик күңелле уйнадык, ял иттек. Өйгә дә кайтыр вакыт җиткәнен сизми дә калганбыз.

**Егетләр:**

Таң атар, чыгар кояшы

Өйләргә таралышыйк,

Хуҗаларга рәхмәт әйтеп,

Дусларым, саубуллашыйк!

**“Орчык бәйрәме”**

**Төркем:** мәктәпкә әзерлек төркеме балалары өчен (6-7 яшь).

**Максат:** милли хәзинәбез булган татар халык йола-бәйрәмнәре турында балаларның белемнәрен арттыру.

**Бурычлар:**

- балаларда милли мәдәнияткә, гореф-гадәтләргә, туган телгә мәхәббәт тәрбияләү;
- сөйләм теленең сәнгатьлелеген, хәтерен һәм уй-фикерен үстерү;
- җырлы-биюле уеннар, мәкальләр өйрәнүне дәвам итү.

**Җиһазлау:** өй күренеше: чигүле пәрдәләр белән тәрәзә, эскәмияләр, идәндә тукыган паласлар җәелгән; орчыклар, сарык йоны, йомгаклар, йоннан бәйләнгән оекбашлар, бияләйләр, татар халык көйләре, ноутбук, колонкалар.

**Бәйрәм барышы:**

**Алып баручы:** Балалар, без бүген бик хөрмәтле кешегә – әбигә кунакка барабыз. Ул безгә “Орчык бәйрәме” турында сөйләр. Безнең халкыбыз хуҗаларга ихтирам йөзеннән кунакка һәрвакыт күчтәнәч белән йөргән. Бу матур гореф-гадәт хәзергә кадәр сакланган. Без дә әбигә күчтәнәчкә чәк-чәк алып барыйк әле.

(балалар өй күренеше янына киләләр).

**Балалар:** Исәнмесез, әбекәй!

**Әби:** Исәнмесез, балакайларым, рәхим итегез! Әйдәгез, әйдә, хуш киләсез, түрдән узыгыз.

**Балалар**: Әби, бездән сезгә кечкенә генә күчтәнәч. Рәхим итеп алыгыз.

**Әби:** Олыласаң олыны, олыларлар үзеңне, - ди халык. Мине олылап килгәнегез өчен барыгызга да рәхмәт, балалар.

**Алып баручы**: Кәефләрең ничек, әбекәй?

**Әби:** Аллага шөкер, әйбәт кенә. Мин сез киләсен белдем бит.

**Бала:** Әллә мендәрләрең ишелеп төштеме?

**Алып баручы**: Мендәрнең нинди катнашы бар монда?

**Бала:** Мендәр ишелсә, кунак килә диләр бит. (*көләләр*)

(кереп утырышалар, әби йон яза)

**Алып баручы:** Әбекәй, безгә орчык бәйрәме турында сөйлисеңме?

**Әби:** “Орчык бәйрәме” – безгә әби-бабаларбыздан калган мирас ул, балалар. Ул кара көз җитеп, җиргә кар төшкәч уздырыла. Хуҗа кеше күп итеп йон әзерләп куя. Кичтән тәм- томнар пешерә. Өмәгә күршеләр, дус-ишләр чакырыла. Бергәләп җыелгач, күмәк эш башлана: кемдер йон яза, кемдер эрли, кемдер йомгак чорный, кемдер бәйли. Эшне бүлешеп эшлиләр. Ә инде күңелсез булмасын өчен, болар барысы да уен-көлке, җыр-бию белән үрелеп бара. Эшләр тәмамлангач, хуҗа эшчеләрен тәмле ризыклар белән сыйлый.

**Бала:** Әби, ә нәрсәгә сезгә шулай күп йон кирәк? *(йон карау)*

**Әби:** мин сезгә оекбашлар, бияләйләр бәйләрмен, Алла боерса. Минем сезнең кебек үк оныкларым бар. Алар мин бәйләгән әйберләрне бик охшатып кияләр. Менә кайберләрен бәйләдем дә инде. *(оекбашлар, бияләйләр күрсәтә).*

**Алып баручы:** И-и-и, карагыз әле балалар, әбекәй, ничек тигез итеп, йон эрләгән. Күрегез әле сез аның орчык тәгәрәтүен. Кулың ятып тора шул эшкә, әбекәй, син эрләгән җептән бәйләгән оекбашлар, бияләйләр бик матур, җылы һәм чыдам була.

**Әби:** Аның бөтен сере – бабаларыбыз ясаган орчыкларда бит. Орчыклар шундый җайлы, кулга ятып торалар. Килегез әле, балакайларым, әйдәгез сезне дә өйрәтәм. Эшләгәннәрегез кеше өчен булса, өйрәнүегез үзегез өчен булыр. *(әби балаларга эш куша: йомгакка җеп чорнау, йон язу...)*

**Әби**: Күпме булышчы! Сөбханалла. Болай булгач, язылмаган бер йон да калмый инде.

**Алып баручы**: Эшкә бирелеп китеп, телдән язмыйк тагын. Әйдәгез, **“Башы телемдә, ахыры төендә”** дигән уенын уйнап алыйк. Мин мәкальнең башын әйтәм, ә сез ахырын:

- Коры табынга, *кунак утыртмыйлар.*
- Эш беткәч, *уйнарга ярый.*
- Әткәй – шикәр, *әнкәй – бал.*
- Тирләп эшләсәң, *тәмләп ашарсың*.
- Кием кешене, *бизи.*

**Әби**: Менә булдырдыгыз, балалар. Эшләгәндә кулыгыз-кулга йокмый, сөйләгәндә телегез дә шулай икән.

**Алып баручы:** Балалар, аякларыгыз утырып оеп киткәндер инде. Әйдәгез әле, ярышып алыйк – йомгакны урап карыйк. Кайсыгыз җитезрәк микән?

**Уен “Кем беренче урый”**

**Әби:** Ай, булдырдыгыз! Без дә яшь чакта, уйнарга ярата идек. Сез “Орчык тәгәрәтешле” уенын беләсезме? Уйныйбызмы?

**“Орчык тәгәрәтешле” уены**

*(Орчык әйләнеп туктагач очлы башы кемгә карый, шул җәза үти)*

**Балалар:** бигрәк кызык уен, әбекәй, рәхмәт. Ә без “Капкалы” уенын уйнарга яратабыз.

**“Капкалы” уены**

**Алып баручы:** Бик күңелле уйнадык, ә хәзер табышмак әйтәм мин сезгә,

Йон бирә нәрсә безгә? (Сарык)

- Әйләнгән саен калыная. (Йомгак)
- Биш агайга бер күлмәк. (Бияләй)
- Кечкенә генә карчык, зыр-зыр әйләнеп йон җыя. (Орчык)

**Әби:** Балалар, мин бит сез килүгә татарларның милли ризыкларын пешергән идем. Ә сез татар милли ризыкларын беләсезме?

**Балалар:** бәлеш, өчпочмак, гөбәдия, чәк-чәк, бавырсак, кыстыбый, пәрәмәч...

**Әби:** Беләсез икән, рәхмәт яугырлары. Ә сез табын янында әдәпле утыра беләсезме?

**Балалар:** Олы кешедән алда табынга утырырга ярамый. Авызда ризык булганда, сөйләшү- әдәпсезлек. Терсәкләрне өстәлгә куймыйлар.

**Әби:** Сезнең тәртипле булуыгызга бик сөендем. Минем дә сезгә әйтер сүзем бар: Ипи валчыгын коеп ашамагыз, ипинең рәнҗүе төшәр. Сыныгыгызны ашап бетерегез, югыйсә бәхетегез калыр. Вакытында туя бел, кашыгыңны куя бел.

Ә хәзер аш бүлмәсенә чыгып, чәй эчеп алыйк. Рәхим итегез!

## “Һәр җәүһәрдә – халкым тарихы” кичәсе

**Төркем:** мәктәпкә әзерлек төркеме балалары өчен (6-7 яшь).

**Максат:** милли җәүһәрләрнең кыйммәтле мирас икәнлегенә төшендерү, аларны

сакларга кирәклеген ассызыклау, балалар күңелендә милли үзаң, милли горурлык хисләре тәрбияләү.

**Әзерлек эшләре:** милли җәүһәрләр күргәзмәсенә әйберләр җыю (чиккән сөлгеләр, кызыл башлы сөлге, читек, милли түбәтәй, калфак, орчык, ашъяулыклар һ.б.), шигырьләр, табышмаклар уку, өйрәнү.

**Җиһазлау:**

Зал матур итеп бизәлгән: өй күренеше - өстәл, татар халык ашлары (бәлеш, өчпочмак, кыстыбый, чәк-чәк һ.б.), "Халкыбызның күңел бизәкләре" дип исемләнгән милли җәүһәрләр күргәзмәсе, татар халык көйләре, ноутбук, колонкалар.

**Алып баручы:** Исәнмесез! Хәерле көн, кадерле балалар, кунаклар! Без бүген борынгы җәүһәрләр, рухи ядкарьләр иленә "сәяхәт итәрбез". Безнең милли җәүһәрләр күргәзмәсендә сезнең әби-бабайларыгызның гаилә җәүһәрләре дә бар. Без алар белән якыннан танышып китәрбез.

Әбиебез сандыгында

Сакланмый ниләр генә

Әйдәгез, карыйк әле -

Нинди хәзинә бар анда.

(күргәзмә янына баралар)

**Алып баручы:** Менә алар – халык җәүҺәрләре! Бөтен дөньяга билгеле булган милли киемнәр. Кем милли киемнәр турында сөйли?

**Бала:** Бу - күлмәк. Татар кызларының милли киеме,.....

**Алып баручы:** Балалар, бала итәкле күлмәктә итәкләре күп булса, күлмәк тә матуррак булган ди. Ә күлмәк өстеннән нәрсә кигәннәр? (*Камзул, чигелгән матур алъяпкычлар кигәннәр*).

**Бала:** Минем дәү әнием дә алъяпкыч кия. Аның алъяпкычлары төрле-төрле.

Алъяпкычымның бизәге

Әллә кайдан күренә.

Аллы-гөлле чәчәк төшкән,

Килешәдер үземә.

**Алып баручы:** Балалар, алъяпкыч берничә төрле булган. Ашарга пешергәндә, печән җыйганда, кунакка барганда кия торган. Челтәрле, чигүле алъяпкыч... Алъяпкыч сүзе – алга ябу сүзеннән алынган. Элек-электән, татар халкы матурлыкка омтылган. Матурлап киемнәр тегеп, аларга матур бизәкләр ясап, чигеп киенгәннәр. Карагыз әле, балалар, нинди матур баш киемнәре. Хатын-кызлар нинди баш киеме кигән?

**Бала:** Калфак - хатын-кызларның баш киеме. (Карыйлар) Бизәкләп, матурлап эшләнгән.

Калфак турында шигырь уку:

Калфак кигән кыз баланың

Багып алчы йөзенә.

Нинди гүзәл татар кызы,

Күз тимәсен үзенә.

**Алып баручы:** Калфакларны алтын-көмеш җепләр белән, энҗе-мәрҗән, сәйләннәр белән дә чиккәннәр. Калфак - иң нәфис, зәвыклы баш киеме. Татар хатын-кызлары яратып башларына яулык та япканнар. Ак төстәге яулык яратканнар! Ак яулык - чисталык, тынычлык билгесе. Элек-электән безнең хатын-кызларыбыз шәл-яулыкны яратып бәйләгәннәр (күргәзмәдәге җәүһәрләрне алып карыйлар). Ир-атларның баш киеме?

**Бала:** Ирләрнең баш киеме – чигүле түбәтәй. Бүген дә түбәтәйне бабайлар, әтиләр, малайлар яратып кияләр.

Түбәтәй турында шигырь уку:

Түбәтәемне кидем,

Көзге каршына килдем.

Менә шундый була ул

Татар малае дидем.

Әйдәгез, уйныйбыз!

**“Түбәтәйле” уены**

**Алып баручы:** Балалар, табышмак әйтәм – җавабын күргәзмәдәге экспонатлар арасыннан эзләгез!

- Яңа гына идем итек, “ч” өстәгәч булдым... (читек).

Бик дөрес, ә беләсезме, аулак өйләргә дә кызлар читекләр киеп йөрергә яратканнар. Карагыз әле, читекнең бизәкләре нинди катлаулы. Мондый бизәк ясар өчен күпме тырышлык кирәк. Читек бик уңайлы, йомшак аяк киеме, шуңа күрә бүгенге көндә дә аны тектереп киючеләр бар.

- Бер тычканга ике койрык. Ул нәрсә? (Чабата).

- Озын-озын озарган, ике башы кызарган. (сөлге)

**Бала** (кызыл башлы сөлге күрсәтә)**:** Бу – кызыл башлы сөлге!

**Алып баручы:** Булдырдыгыз.

Татар хатын-кызларыбыз
Эшнең серен белгәннәр,
Кич утырып, җырлар җырлап,
Оста чигү чиккәннәр.

Хатын-кызлар бик теләп кул эшләре белән шөгыльләнгәннәр: тукыма тукыганнар, кием теккәннәр, бизәкләп чиккәннәр. Тәрәзә пәрдәләре, мендәр тышлары, ашъяулыклар әзерләгәннәр. Бу бик авыр, күп вакыт ала торган хезмәт булган. (сөлгеләр күрсәтелә). Таҗлар, каурыйлар, төрле чәчәкләр, йөрәк сүрәтләре – һәммәсе дә бар анда! Ә менә монсы чиккән кулъяулык. Карагыз әле, никадәр хезмәт, күңел җылысы салынган бу бизәкләргә.

**Уен уйнау: “Яшерәм яулык”.**

- Зыр-зыр әйләнә, һәркемне киендерә. (Орчык).

**“Орчык бөтерү” уены.**

**Алып баручы:** Татар хатын-кызлары электән төрле бизәнү әйберләре тагып йөрергә яратканнар. Алка, беләзек, йөзек, чулпылар, брошкалар такканнар. Бу нәрсә? (күкрәкчә күрсәтә) Күкрәкчә күз тиюдән саклаган. Аны төсле ташлар, сәдәфләр, төрле тәңкәләр белән бизәгәннәр.

Хәзерге заман бизәнү әйберләре элеккеләреннән бик нык аерыла. Ләкин соңгы елларда татар орнаментларын кулланып, милли алкалар, йөзекләр, итекләр, сумкалар да чыгара башладылар. Татар орнаментлары булган киемнәрне кию туган телне, милләтне саклап калырга, аның тарихын истә тотарга ярдәм итә.

**Тәрбияче:** Балалар, рухи ядкарьләребезне ешрак карыйк, аларның тарихы белән кызыксыныйк. Әби-бабаларыбызның гореф-гадәтләрен, җыр-биюләрен, үзебезнең туган телебезне – татар телен онытмыйк.

Хәтерләүдән курыкма син,
Үткәнеңне онытма син.
Бел син ерак бабаларның,
Ни иккәнен, ни чиккәнен,
Нинди моңнар, нинди көйләр,
Безгә калдырып киткәнен.

# Татар халык уеннары

## Зәңгәр чәчәк

*Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәк ясыйлар. Бер бала, чигүле кечкенә мендәр тотып, уртага чыгып баса. Балалар түгәрәк буенча җырлап әйләнәләр:*

Юл читендә зәңгәр чәчәк
Якты нурлар тарата.
Безнең кызлар һәм малайлар Зәңгәр
чәчәк ярата.

*Туктап биеп-җырлап торалар, ә уртадагы бала, мендәр тотып, түгәрәк буенча биеп йөри:*

Якын дуслар арасыннан
Берсен сайлап ал әле.
Тезләреңә ипле булыр -
Мендәреңне сал әле.

*Мендәр тоткан бала мендәрен бер бала алдына куя һәм, тезләнеп, аңа кулын бирә. Ул бала аның тирәли әйләнә, башкалар кул чабып торалар.*

## Чума үрдәк, чума каз

*Уйнаучылар кара-каршы ике рәт булып тезеләләр, парлашып кулга-кул тотыналар. Рәт башында  бер ялгыз уенчы басып тора. Балалар барысы бергә җырлыйлар:*

Чума үрдәк, чума каз,
Тирән күлне ярата ул, ярата.
Алия үзенә иптәш эзли,
Белмим, кемне ярата шул, ярата.
Дамирны ярата шул, ярата.

*Уйнаучылар, җыр ритмына туры китереп, хәрәкәтләнеп торалар. Ялгыз бала (Алия), рәт арасыннан узып, үзенә бер иптәш сайлый һәм аны (Дамирны) җитәкләп ахырга барып баса. Үз парыннан аерылган уйнаучы рәт башына китә.*

*Уен шулай дәвам итә.*

**Түбәтәйле**

*Уртада 5-6 урындык тора, урындыкларга түбәтәйләр куела. Балалар урындыклар тирәли басалар һәм, көй башлануга, җиңелчә йөгерә башлыйлар. Көй туктауга, түбәтәйләрен кияләр, шул арада урындыкларга утырып өлгерергә тиешләр.*
*Кем урынсыз кала, шул уеннан чыга. Икенче мәртәбә уйнаганда. Уртада өч урындык кала, уйнаучылар саны артыграк була.Соңга таба бер урындык калдыралар. Шулай итеп, иң игътибарлы, җитез бала билгеләнә.*

**Җырлы уен "Кунаклар"**

*(Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә басалар)*

Ямьле матур көн иде,

Чакырдык без кунаклар.

Кунакларны сыйларга,

Салдык майлы коймаклар.

Чыж-чыж итеп коймаклар *(Балалар кулларын як-якка җәяләр),*

Җәелде, әй, җәелде.

Менә тагын кечкенә

Булып калды, җыелды (*Кысылалар),*

Җыелды, әй, җыелды.

Аннан ары кабарды *(Кулларын югары күтәрәләр),*

Кабарды,әй, кабарды.

Шиңде, юп-юка калды (*Чүгәлиләр),*

Пеште инде коймаклар.

Сыйландылар кунаклар,

Тордылар, баш иделәр *(Баш ияләр.)*

Таралдылар, әй, шатлар.

## Яшерәм яулык

*Балалар түгәрәк ясап басалар. Кулларын артка куялар. Санамыш ярдәмендә яулык салучы билгеләнә. Аның кулында кулъяулык. Ул, түгәрәктән чыгып, шушы сүзләрне җырлап йөри:*

Кулъяулыгым яшел, яшел,
Яшел чирәм астында.
Сиздермичә ташлап китәм
Бер иптәшем артына.

*Сүзләрне әйткәндә, бер баланың уч төбенә кулъяулыкны калдырып китә. Үзе түгәрәк эченә кереп баса. Кулъяулыклы бала, тиз генә артка чыгып, сүзләрне әйтә-әйтә, уенны дәвам итәргә тиеш. Әгәр ул тоткарланып торса яки кулъяулык салганны сизмәсә, аңа җәза бирелә.*

## Башмакчы

*Балалар түгәрәк ясап басалар. Берәү башмакчы була. Ул, кулына парлы башмак алып (башмак уйнаучы балаларның аяк размерыннан зуррак булырга тиеш), уртага чүгәләп чигеп утырганын күрсәтә. Калган балалар, түгәрәк буйлап йөреп, җыр җырлыйлар:*

Төрле һөнәр беләбез,
Матур итеп тегәбез;
Асыл төсле җепләр белән
Башмак башын чигәбез.
Әй, башмакчы, башмакчы,
Үзең оста такмакчы.
Син җырлама такмагын,
Бир кияргә башмагын.

*Балалар җырлап бетергәч, уртадагы бала башмакларны ике бала арасына куя һәм аларның иңнәренә кагыла. Ике бала ике якка түгәрәк буйлап йөгереп китәләр. Кем беренче килеп җитә, шул башмакларны кия һәм уртага биергә чыга. Ул башмакчы була. Уен яңадан башлана.*

## Утыр, утыр, Мәликә

*Балалар түгәрәккә басалар. Берәү, күзен бәйләп, түгәрәк уртасына утыра. Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәктә җырлап әйләнәләр:*

Утыр, утыр, Мәликә,
алмагачның төбенә,
Кем утырган каршыңа, әйтеп
бирче тиз генә.

*Берәү аның янына килеп утыра. Уртадагы бала аны капшап танып исемен әйтергә тиеш. Әгәр белмәсә, аңа җәза бирелә. Уен шул рәвешчә дәвам итә.*

## Капкалы

*10 пар җитәкләшеп зур түгәрәк ясап басалар. Парлар җитәкләшкән килеш кулларын өскә күтәреп капка ясап торалар. Көй башлануга арадан бер пар үзе теләгән капкага керә, алар урынына баса, әлеге пар икенче капкага бара. Көй туктауга капкага керергә өлгерми калган пар җәза ала.*

## Яулык салыш

(*милли көй яңгырый, балалар түгәрәктә. Көй башлануга яулык кулдан-кулга түгәрәк буйлап җибәрелә. Көй туктауга яулык кемдә кала, шул җәза ала*)

**Капкалы (җырлы-биюле түгәрәк уены)**

*(Уен "Иделләре, күлләре " көенә бара)*

*Балалар җитәкләшеп зур түгәрәктә җырлап йөриләр (бер пар түгәрәк эчендә):*

Әйдә безгә килегез,

Капкалардан керегез,

Капкалардан керегез.

*Балалар туктап кулларын өскә күтәреп капка ясыйлар, җырны дәвам итәләр (түгәрәк эчендәге пар капкалардан йөри)*

Өебезгә үтегез,

Өебезгә үтегез,

Җырлап бәйрәм итегез,

Жырлап бәйрәм итегез,

Кунак булып китегез!

*Җырлап бетергәч капка ябыла, ике пар уртага чыгып әйләнә.*